| ГЛАВА БОЛЬШЕРУСАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ УРСАК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 елның 12 ноябре Олы Урсак авылы № 3

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы
Олы Урсак авыл җирлегенең Кече Урсак авылында
гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе
буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федеральзаконның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлеге Уставының 22 статьясына туры китереп КАРАР КЫЛА:

1.2024 елның 24 ноябре 11 сәгать 00 минутка Кече Урсак авыл клубы бинасында Кече Урсак авылы, Усманов урамы, 46 нчы йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең Кече Урсак авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: "Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең Кече Урсак торак пункты территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум(биш йөз) күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ки торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмиятле гомуми файдаланучы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау;
- су белән тәэмин итү һәм су җибәрү системаларын, су ташу манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, ташуын һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү, һәм ремонтлау? ".

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Русак авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә

« ӨЧЕН»　　　　　　　　　　«КАРШЫ»

3.Әлеге карарны Олы Урсак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга .http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Урсак авыл җирлеге башлыгы　　　　Зиннәтуллтин Г.А.